**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ___________ ПР-244 27.11.2025 КАРАР №____

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2018 елның 27 августында кабул ителгән 205 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августындагы «Административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 205 номерлы карарына Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында

«хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «Белешмә» сүзенә алмаштырырга;

1.2. 3.1 пунктның «д» пунктчасына түбәндәге абзацлар өстәргә:

Банкротлык турында Бердәм федераль реестрдан гражданның судтан тыш банкротлык процедурасын тәмамлау турында белешмәләр булган документ.

амнистия турында акт яки штраф формасында җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев